# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «СӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«16» июнь 2021 ел № 12/1

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Сәмәкәй авыл җирлеге» территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2020 елның 30 ноябрендәге 02-06-2020/9 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Сәмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. Муниципаль берәмлек Советының 2012 елның 11 октябрендәге «Татарстан Республикасы «Сәмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 22 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Сәмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Кагыйдәләрнең 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзацларны өстәргә:

- «каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ оператор (алга таба – региональ оператор) – каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча оператор – каты коммуналь калдыклар милекчесе белән региональ оператор эшчәнлеге зонасында барлыкка килә һәм туплана торган каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәт күрсәтүгә шартнамә төзергә тиешле юридик зат;

- калдыкларны урнаштыру – калдыкларны саклау һәм күмү;

- калдыкларны саклау – калдыкларны утильләштерү, зарарсызландыру, күмү максатында унбер айдан артык вакытка махсуслаштырылган объектларда туплау»;

2) 2 өлешнең 37 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«янәшә территория – бина, төзелмә, корылма, җир кишәрлеге янәшәсендәге гомуми файдаланудагы территория, мондый җир кишәрлеге төзелгән һәм чикләре Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртип нигезендә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән очракта»;

3) Кагыйдәләрнең 2 өлешендәге 25, 26, 38, 44 абзацларны төшереп калдырырга;

4) Кагыйдәләрнең 3.7.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм эш итү буенча башка эшчәнлек региональ оператор тарафыннан калдыклар белән эш итүнең территориаль схемасы нигезендә тәэмин ителә.».

5) 3.7.5 һәм 3.7.7 пунктларын төшереп калдырырга;

6) Кагыйдәләрнең 3.16 пунктында «3.7.1 пункты белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) Кагыйдәләрнең 3.9 пунктындагы 1 һәм 2 абзацларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъекты территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү региональ операторлар тарафыннан калдыклар, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә региональ программа һәм каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә кулланучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә калдыклар белән эш итүнең территориаль схемасы нигезендә тәэмин ителә.

Региональ оператор каты коммуналь калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшләрен мөстәкыйль рәвештә яки каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторларны җәлеп итеп башкара.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә шартнамә кулланучы һәм эшчәнлек зонасында каты коммуналь калдыклар барлыкка килгән һәм аларның туплану урыннары (мәйданчыклары) булган региональ оператор арасында төзелә.

Региональ оператор каты коммуналь калдыклар белән эш итү өчен бу калдыкларны чүп ташу транспортына төягән мизгелдән җаваплы.»

8) Кагыйдәләрнең 4.4 пункты 4.4.2 пунктчасының 2 абзацын төшереп калдырырга;

9) Кагыйдәләрнең 9.11 пунктын төшереп калдырырга;

10) Кагыйдәләрнең 3.5.2 пунктында «7.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр» сүзләрен «эш көннәрендә 06.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр, ә ял һәм эшләми торган бәйрәм көннәрендә 09.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр» сүзләренә алыштырырга;

11) Кагыйдәләрнең 8.2.3 пунктында «23.00 сәгатьтән 7.00 сәгатькә кадәр» сүзләрен «эш көннәрендә 22.00 сәгатьтән 6.00 сәгатькә кадәр, ә ял һәм эшләми торган бәйрәм көннәрендә 22.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр» сүзләренә алыштырырга;

12) Кагыйдәләрнең 9.15 пунктындагы 9 абзацны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Сәмәкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http//pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Сәмәкәй авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе — И.М.Усманов